**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ЛАИШЕВСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
СОВЕТ ГОРОДА ЛАИШЕВО**

422610 г.Лаишево,
ул. Коммунальная, д.3
тел: 8-(84378) -2-50-62
факс: 8-(84378) -2-50-62

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛАЕШ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЛАЕШ ШӘҺӘР СОВЕТЫ**

422610 Лаеш ш.,
Коммунальная ур., 3 нче йорт
тел: 8-(84378) -2-50-62
факс: 8-(84378) -2-50-62

2023 елның 10 мае 57 номер

# КАРАР

**«Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын раслау турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә, 2023елның 21 апрелендәге гавами тыңлаулар беркетмәсен, гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында 2023нче елның 2 маендагы бәяләмәне карап, Лаеш шәһәре Советы карар кылды:

1. «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә, ял, туризм һәм спорт объектларының шәһәр төзелеше регламентлары өлешендә (Р3), үзгәрешләр кертү проектын расларга.
   - рөхсәт ителгән файдалануның төп төрләрендә түбәндәге рөхсәт ителгән куллану төрләре буенча катлар саны буенча чикләүләрне бетерергә: «иҗтимагый туклану» (код-4.6), «кунакханә хезмәте күрсәтү» (код-4.7).
   - файдалануның шартлы төрләрендә түбәндәге рөхсәт ителгән куллану төрләре буенча катлар саны буенча чикләүләрне бетерергә: «кибетләр» (код-4.4), «банк һәм иминият эшчәнлеге» (код-4.5).
2. Әлеге карарны “Кама ягы”(«Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп тору Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Лаеш шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе В.А.Арефьевка йөкләнә.

**Башлык – Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районының**
**Лаеш шәһәре Советы рәисе** **И.Ф.Зарипов**